**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4267**
**19.08.2019**

Башкарма комитетның 2018 елның 29 ноябрендәге 7122 нче карары белән расланган эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2019 елның 1 апрелендәге 50-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2018 елның 29 ноябрендәге 7122 нче карары белән расланган эчке муниципаль финанс контроле органы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контроль эшчәнлеген гамәлгә ашыруның административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6 пунктча белән тулыландырырга:

«6) үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда дәүләт сере булып саклана торган мәгълүматларны һәм федераль законнарда каралган очраклардан кала, федераль законнар нигезендә алу чикләнгән башка мәгълүматны алганда, аларны ачып салмаска.»;

2) 6 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 12 пунктча белән тулыландырырга:

«12) үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда дәүләт сере булып саклана торган мәгълүматларны һәм алу чикләнгән башка мәгълүматны алганда, аларны ачып салмаска.»;

3) 8 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) бердәнбер куючы (подрядчы, үтәүче) белән төзелгән контрактның башлангыч (максималь) бәясен, товар, эш, хезмәт берәмлегенең башлангыч бәясен, товар, эш, хезмәт берәмлекләре бәяләренең башлангыч суммасын билгеләү һәм нигезләүләр;»;

4) 26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26) Планнан тыш тикшерүләр Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары боерыгы белән түбәндәге нигезләрдә үткәрелә:

1) сатып алуда катнашучының заказчы, вәкаләтле орган, вәкаләтле учреждение, махсуслаштырылган оешма, электрон мәйданчык операторы, махсуслаштырылган электрон мәйданчык операторы яки сатып алуларны гамәлгә ашыра торган комиссияләр, аларның әгъзалары, контракт хезмәтенең вазыйфаи затлары, контракт идарәчесенең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаять ителгән мөрәҗәгать алу. Мондый шикаятьне карап тикшерү 44-ФЗ санлы Законның 6 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла, 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсенең 15.1 бүлегендә каралган эш итүләргә (эш итмәүләргә) шикаять итү очрагыннан кала. Планнан тыш тикшерү сатып алуда катнашучының шикаяте нигезендә үткәрелгән очракта, әлеге тикшерүне үткәрү һәм мондый шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча бердәм карар кабул ителә;

2) Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы башка норматив хокукый актлар бозылу хакында мәгълүмат алу, шул исәптән:

- физик затның, юридик затның яисә җәмәгать берләшмәсенең җәмәгать контролен гамәлгә ашыра торган яки юридик затлар берләшмәләренең Россия Федерациясе законнарын бозу һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы башка норматив хокукый актлар бозылу билгеләре булу хакында күрсәтелгән гаризалары һәм хәбәрләре;

- контрольлек итүче орган тарафыннан сатып алулар өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы башка норматив хокукый актлар бозылу ачыклану;

- массакүләм мәгълүмат чараларының Россия Федерациясе законнарын бозу һәм сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы башка норматив хокукый актлар бозылу билгеләре булу хакында күрсәтелгән хәбәре;

3) 44-ФЗ санлы Законның 99 маддәсендәге 22 бүлекнең 2 пункты нигезендә үтәү өчен бирелгән элекке срокның чыгуы.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин